ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР ЯМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423753, Татар Ямалы авылы,
Ленин ур.,6 нчы йорт.
Тел/факс 5-75-19

СОВЕТ ТАТАРСКО-
ЯМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423753, село Татарские Ямалы,
ул.Ленина,дом 6.
Тел/факс 5-75-19

КАРАР РЕШЕНИЕ

от 22.11.2019 г. №33

**Татар Ямалы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 21.11.2019 елгы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Татар Ямалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татар Ямалы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан кала, 2020 елда үзара салымның бер тапкыр 500(Биш йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Күмү урыннарын карап тоту;

- Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

* юлларны формалаштыру һәм тигезләү, ком һәм таш салу;, грейдер белән тигезләү, кардан чистарту, юлбилгеләре урнаштыру;

- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү һәм су чыганакларын документаль рәсмиләштерү;

- Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру;

2. Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Татар Ямалы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Татар Ямалы
авыл җирлеге башлыгы Д. Ф. Вәлиев